ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:
«авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларга;
авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган гаиләләргә.»;

2) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:
«4. Әлеге Законның $8^2$ статьясында билгеләнгән социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән органына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә башкарыла.»;

3) түбәндәге эчтәлекле $8^2$ статья өстәргә:

«$8^2$ статья. **Авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларга һәм авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм чаралары**

1. Торак урыннарга мохтаҗ дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан, Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларга, шулай ук әлеге исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган гаиләләргә торак урын сатып алу өчен торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) бирелә.

2. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән инвалидларның һәм инвалид балаларның «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 17 статьясындагы алтынчы өлешендә каралган өстәмә торак мәйданына хокукы булганда, торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) мондый хокукны исәпкә алып бирелә.

3. Торак субсидиясен (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне) исәпләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.»;

4) 9 статьяның 1 пунктында «$8^1$» санын «$8^2$» санына алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2014 елның 23 июле
№ 69-ТРЗ